**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

**КАРАР**

2015 елның «09» октябреннән № 279

**«Муниципаль мөлкәтне милеккә сату буенча бәяне күтәрүгә ачык аукцион оештыру һәм үткәрү турында»**

Муниципаль мөлкәтне нәтиҗәле файдалану максатыннан 2006 елның 26 июлендәге 135-ФЗ номерлы «Көндәшлекне яклау турында» гы Федераль законга, 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» гы Федераль законга, РФ Граждан кодексына, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Уставына таянып, **карар бирәм:**

1. Муниципаль мөлкәтне милеккә сату буенча бәяне күтәрүгә ачык аукцион рәвешендә сатулар үткәрергә:

1номерлы лот Татарстан Республикасы, Яңа Чишмә муниципаль районы, Акъяр авылы, Совет урамы, 22 нче йорт адресы буенча урнашкан, Татарстан Республикасы, Яңа Чишмә муниципаль районы, Акъяр авыл җирлеге муниципаль милкендә булган дәүләт номеры Р 898 О 16 RUS, 2005 елгы ВАЗ - 21140 маркалы җиңел автомобиль;

2 номерлы лот Татарстан Республикасы, Яңа Чишмә муниципаль районы, Яңа Чишмә авылы, Совет урамы, 80 йорт адресы буенча урнашкан, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы муниципаль милкендә булган дәүләт номеры В148 ХР 16 RUS, 2002 елгы, ВАЗ-21074 маркалы җиңел автомобиль;

3 номерлы лот Татарстан Республикасы, Яңа Чишмә муниципаль районы, Яңа Чишмә авылы, Совет урамы, 80 йорт адресы буенча урнашкан, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы муниципаль милкендә булган дәүләт номеры Р580 ХР 16 RUS, 2005 елгы маршрутларда пассажирлар йөртү өчен 15 урынга исәпләнгән автобус.

2. Әлеге карарның 1 нче кушымтасында күрсәтелгән муниципаль мөлкәтне милеккә сату буенча бәяне күтәрүгә ачык аукцион үткәрү буенча аукцион комиссиясе составын расларга.

3. Аукционның башлангыч бәясен шәхси эшмәкәр Т. Г.Князев ясаган бәйсез бәяләү нигезендә билгеләргә:

1номерлы лот 58000,00 (Илле сигез мең сум 00 тиен)

2номерлы лот 20000,00 (Егерме мең сум 00 тиен)

3номерлы лот 94000,00 (Туксан дүрт мең сум 00 тиен)

4. Әлеге карарның 3 пунктында каралган башлангыч бәянең 5 проценты күләмендә «Аукцион адымы» билгеләргә.

5. Ачык аукционда катнашучылар өчен задаток суммасын әлеге карарның 3 пунктында каралган башлангыч бәянең 20 проценты күләмендә расларга.

6. «Яңа Чишмә хәбәрләре» район газетасында муниципаль мөлкәтне милеккә сату яки аны әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән муниципаль милеккә сату буенча ачык аукцион үткәрү турында хәбәр бастырырга.

7. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетына әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән муниципаль мөлкәтне милеккә сату бәясен күтәрүгә ачык аукцион үткәрергә.

8. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына үткәрелгән ачык аукцион нәтиҗәләре буенча сатуларда җиңүчеләр белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән муниципаль милеккә сату-алу шартнамәсен төзергә.

**Яңа Чишмә муниципаль районы**
**Башкарма комитеты**
**җитәкчесе** **Р.Р. Фасахов**

Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитетының
2015 елның«09» октябрендәге
279  номерлы карарына
1 нче кушымта

**Муниципаль милекне сату буенча аукцион комиссиясе составы**

**Комиссия рәисе:**

Исхакова Л.К. - Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары

**Комиссия әгъзалары:**

Гордеева Н.А. - Яңа Чишмә муниципаль районының Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе

Завалишина Л.Л. - Яңа Чишмә муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы рәисе

Митько А.В. - Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының муниципаль заказ бүлеге башлыгы

Попкова Н.В. - Яңа Чишмә муниципаль районының Милек һәм җир мөнәсәбәтләре Ппалатасының әйдәп баручы белгече

Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитеты
эшләре белән идарә итүче М.Д. Губкина